**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
14.08.2020 ел

КАРАР
№ 224

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында " 21.10.2019 елдагы 165 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

01.04.2020 елдагы № 103-ФЗ “Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында”, 22.04.2020 елдагы № 120-ФЗ, “Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында” гы Федераль законнары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» 21.10.2019 елдагы № 165 (14.04.2020 елдагы № 199 үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 9 статьяның 2 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга;

1.2. 19 статьяның 2 пунктында “һәм үтәләләр” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 24 статьяның 4 пунктында “һәм үтәлә” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 24 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия белән мөлкәтләре район (Гарант) милкендә булган хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре (өлешләре), ә гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмаган Россия Федерациясе дәүләт гарантиясе белән шулай ук дәүләт корпорациясе яисә Россия Федерациясе тарафыннан гамәлгә куелган (төзелгән) дәүләт компаниясе йөкләмәләре тәэмин ителергә мөмкин.”;

1.5. 24 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11. Кредит (заем, шул исәптән облигация) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль Гарант бары тик муниципаль гарантта күрсәтелгән төп йөкләмә шартларын гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртә алмаган һәм (яисә) кредит (займ, шул исәптән облигацион) акчаларыннан максатчан файдаланмаган очракта гына Гарант тарафыннан кире алынырга тиеш., Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә кредитор тарафыннан кредит акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тоту гамәлгә ашырыла.”;

1.6. 24 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

1.7. 24 статьяның 21 пунктындагы 3 пунктчасына “(Россия Федерациясе Бюджет кодексының 116 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш)” сүзләрен өстәргә;

1.8. 24 статьяның 21 пунктындагы 6 пунктчасында “гарантияне үтәү турында гарантка таләп” сүзләреннән соң “(Россия Федерациясе Бюджет кодексының 116 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш)” сүзләрен өстәргә;

1.9. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 35 статьяның 2 абзацының гамәлдә булуын туктатып торырга;

1.10. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 43 статьяның 12 абзацының гамәлдә булуын туктатып торырга;

1.11. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 45 статьяның 7 абзацының гамәлдә булуын туктатып торырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе Г.Г. Хәкимов